

# КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР

**№ 1-2 2025 ел**

***98 нче татар – рус урта гомуми белем бирү мәктәбе***

**Хөрмәтле укытучылар, укучылар, әти-әниләр!**

Сезне 1 сентябрь- Белем бәйрәме һәм яңа уку елы башлану белән чын күңелдән котлыйбыз! Белем көне – искиткеч, гаҗәп бәйрәм. Укытучымы сез, укучымы, көзнең бу беренче бәйрәме һәркем өчен якын. Ул сезне укытуга һәм укуга рухландырсын! Әти-әниләрне укучылар үзләренең уңышлары белән гел куандырып торсын! Тормышыгызда бик күп шатлыклы вакыйгалар булсын, бөтен изге теләкләрегез чынга ашсын! Барыгызга да саулык-сәламәтлек, уңышлар теләп калабыз!



Туган якның һәрбер мөктәбендә

Каршылыйлар Белем бәйрәмен.

Балаларның шат авазы яңгырый,

Кулларында чәчәк бәйләме.

Чыңлый бүген һәрбер төбәктә

Көмеш кыңгырау чыңы.

Мәктәпләргә рәхим ит, әйдә,

2025-2026 нчы уку елы!



**Сүз - бер көнлек, тел - гомерлек**

**Тел турында күренекле язучы һәм шагыйрьләребезнең фикерләре**

Тел- халыкның акылын, гореф-гадәтен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, тарихын, кыскасы, бөтен күңел байлыгын, мең еллар буена үзенә сеңдерә килеп, безнең заманнарга җиткергән чиксез кадерле хәзинә.

(Г.Бәширов)

Без, татарлар, телебез татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул.

(К.Насыйри)

Телне без иң камил бер аралашу коралы, кешелек дөньясын алга әйдәүче бер прогресс чарасы дибез. Тел ул буыннан-буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк иң мәкатдәс бер мирас булып, телен җуймаган милләтләрнең өстә ярылып яткан бердәнбер сыйфаты, билгеседер.

(Х.Сарьян)

Туган ил, туган тел сүзләре һәрвакыт бергә яшиләр, аерылгысыз булып яшиләр.

(Сибгат Хәким)

Телнең төп җирлеге- җәмгыять, кешеләрнең коллектив хезмәтле тормышы. Ул шунда үсә, шунда яши.

(Г.Алпаров)

**Китап- тормыш көзгесе.**

Мин китаплар укырга яратам. Безнең өй тулы китап. Әни миңа туган көнемдә дә, бәйрәм көнендә дә китаплар бүләк итә. Ул минем белемле, тәртипле һәм тәрбияле булып үсүемне тели. Шигырьме ул, хикәяме яисә әкиятме, аларда без тормышның матур якларын күрәбез. Без уңай геройлар кебек әдәпле сөйләшергә өйрәнергә, үзебезне бизи торган матур эшләр башкарырга өйрәнәбез.

Китап геройларындагы аерым бер сыйфатлар миндә дә бар. Габдулла Тукайның “Эш беткәч, уйнарга ярый” шигырендәге кебек дәресемне хәзерләп бетермичә урамга уйнарга чыкмыйм. Шагыйрьнең Акбае кебек иренгәләп тә куйгалыйм. Абдулла Алишның Сертотмас үрдәгедәй сөйләшкәлим дә. Шәүкәт Галиевның Шәвәлие кебек беркатлы да мин. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасындагы Йосыф кебек гафу да итә белүче мин.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: безнең төп эшебез -уку. Шуңа күрә, тырышып укыйк, китапдарның тормыш көзгесе икәнен онытмыйк! Бары тик белемле кеше генә зур уңышларга ирешә ала.

**8А сыйныф укучысы Вәлиев Салават**



## Мәктәбем һәм укытучыларым

Мәктәп юлы-хөрмәт юлы,
Белемгә илтә безне.
Белем һәм тәрбия туплап
Шатландырырбыз сезне.

Менә сагынып көтеп алган 1 нче сентябрь бәйрәме дә килеп җитте. Мәктәбебезне, укыткан укытучыларыбызны, сыйныфташларыбызны бик сагынып килдек.

Мин 7Б сыйныфында укыйм. Сыйныфымда 29 укучы. Малайлар да, кызлар да бездә бик тырышып укыйлар. Сыйныф җитөкчебез - Динә Вафиевна. Ул безнең укуыбызны һәм тәртибебезне гел барлап тора. Безгә физик тәрбия дзресләрен укыта. Сыйныф җитәкчебез белән дәрестән тыш чараларда бик актив катнашабыз. Мин үзем музыка түгәрәгенә йөрим. Скрипкада бик матур итеп татарча, русча, инглизчә көйләр башкарам. Татар теле һәм әдәбияты укытучыбыз Гөлнур Наиловна татар әдәбияты дәресләрендә һәм төрле кичәләрдә дә миңа татар көйләрен уйнаттыра. Мин татар композиторларының көйләрен аеруча яратып башкарам. Ул көйләрне уйнаганда күңелгә рәхәт булып китә.

Безне укыткан укытучыларыбызга бик зур рәхмәтебезне белдерәбез! Нинди генә фәнне алсак та, һәрбер укытучы үз фәнен җиренә җиткереп укучыларга җиткерә. Укытучыларыбызны бәйрәм белән котлыйбыз. Аларга киләчәк тормышларында саулык-сәламәтлек, уңышлар, бәхетле тормыш телибез.

Без юлларга чыктык кына,
Күңелдә якты теләк.
Иң дөрес һәм туры юлны
Сайлашырга сез кирәк.
Боекмас өчен күңелләр
Кимсенмәс өчен йөрәк-
Сез кирәк, укытучылар,
Безгә һәрчак сез кирәк.

**7Б сыйныф укучысы Исмәгыйлева Зәринә**






**Редколлегия:**

**Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Әмирхан Еники, 23.**
**Тел: 8 (843) 236-24-12**

**Сездән язмалар көтеп калабыз!**